Мордовиядә полиция хезмәт-кәрләре мәктәп укучылары һәм педагоглар белән мошенниклыкка каршы профилактик эш алып бара.     Информ мәгълvмат-телеком-муникация технологияләрен кулланып кылынган жинаятьләрне кисәтv максатларында Мордовия эчке эшләр органнары хезмәткәрләре халык белән профилактик әнгәмәләр vткәрvне дәвам итә.
Яна уку елы башлану белән полиция хезмәткәрләренен аерым игътибары гомуми белем бирv оешмаларына бирелә. Профилактик чаралар укучыларга да, педагогик хезмәткәрләргщ дә кагыла. Мәктәп укучылары белән очрашулар кысаларында полиция хезмәткәрләре дистанцион мошенниклыкнын топ схемаларын, шикле шалтыратулар һәм хәбәрләр килгәндә эш итv тәртибен анлаталар, шулай ук шәхси мәгълvматларны һәм банк карталары турында белешмәләрне оченче затларга тапшырырга ярамый дип кисәтәләр. Балигъ булмаганнарны хокукка каршы эшчәнлеккә жәлеп итvгә аерым игътибар бирелә. Полиция хезмәткәрләре яшvсмерләргә банк карталарын һәм акчаларны оченче затларга тапшырган очен Россия Федерациясе законнары нигезендә жаваплылык алырга момкин, дип анлата.
Педагогик хезмәткәрләр белән мошенниклык гамәлләрен башкарунын яна ысуллары, шул исәптән белем бирv оешмалары житәкчеләре исеменнән шалтыратулар һәм хәбәрләр керv очраклары, шулай ук ялган ата-аналар чатлары булдыру турында анлату эшләре алып барыла. Педагогларга алынган мәгълvматны укучыларнын ата-аналарына кичекмәстән житкерv кирәклеге турында хәбәр ителә.
Полиция хезмәткәрләре финанс куркынычсызлыгы чараларын vтәv кирәклеге турында искәртәләр: чит затларга банк карталары реквизитларын, СМС-хәбәрләрдән һәм парольләрдән кодларны хәбәр итмәскә, vзләрен банк яки хокук саклау органнары хезмәткәрләре дип атаган затлар кvрсәтмәсе буенча акчалата операцияләр башкармаска, килгән мәгълvматны кредит оешмаларынын һәм дәvләт органнарынын рәсми элемтә каналлары аша тикшерергә.
Мордовия Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы искәртә: сезгә яки якыннарыгызга карата мошенниклык белән бәйле хокуксыз гамәлләр кылынган очракта, кичекмәстән эчке эшләр территориаль органынын дежур частена яки ашыгыч оператив хезмәтләрне бердәм чакыру номеры «112» буенча морәжәгать итәргә кирәк.